Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге Екатериновка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

28 ноябрь, 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлегенең Екатериновка торак пунктында 2021 елның 28 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 62 (алтмыш ике).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 36 (утыз алты).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 32 (утыз ике).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 4 (дүрт).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2022 елда Екатериновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Екатериновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Екатериновка авыл җирлеге башлыгы *Жуков* А.Н. Жуков